Татарстан Республикасы Спас муниципальрайонының
Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№ 22 22.09.2021

«Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендэге №19 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 27 июлендэге №19 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Өчкүл авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктының икенче - унынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта федераль мәгълүмат адреслы системасының дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм эксплуатациясенә бәйле рәвештә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән файдаланыла.

1.2. 1.5 пунктының унберенче һәм унҗиденче абзацлары өченче һәм тугызынчы абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «һәм»сүзенә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы»сүзләренә алмаштырырга.;

1.5. 2.6.4 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында: www. spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru.) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Өчкүл авыл җирлеге башлыгы Н.В. Емелюшина

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТРЕХОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ